وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№18 (115). 16 декабрь 2011 / 21-мөхәррәм-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




Бөгелмә мөхтәсибе: "Эшләнгән эшләр күп, ләкин эшләнәсе эшләр тагын да күбрәк..."

▷2◁



Ислам – сәламәт яшәү чыганагы

▷3◁



Рүзәл ЮСУПОВ: "Татар халкының рухы нык"

▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘР УНКӨНЛЕГЕ

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды инвалидлар ункөнлегенә багышлап хәйрия чаралары үткәрде. Бересеннән алып унынчы декабрьгә кадәр фонд вәкилләре мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр белән очрашып, рухи-әхлакый темаларга әңгәмәләр оештырды, бүләкләр тапшырды. Күзләре начар күргән инвалидларга "Вкуснотеевъ" продукциясе бүләк ителде.

### МАНАРА ТОРГЫЗЫЛДЫ

11 декабрь көнне Болгар шәһәрендәге Җәмигъ мәчет манарасына реконструкция ясалды. Манараны үзгәртеп коруга шәхси эшмәкәр Мәгърифәтуллин Нәзгать хаҗи булышлык күрсәткән.

Чарада Спас район башлыгы Камил Әсхәт улы Ногаев, район имам-мөхтәсибе Фәргат хәзрәт Минсагиров, көньяк төбәк казые Алмаз хәзрәт Шәрифуллин, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең гомуми бүлек җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, Яңа Чишмә, Нурлат, Аксубай, Чистай районы имаммөхтәсибләре һәм Спас районы имамнары катнашты.

### МӨНӘҖӘТ ҺӘМ НАМАЗ УКУ БУЕНЧА КОНКУРСЛАР ҮТТЕ

11 декабрьдә Ютазы районының Урыссу авылында Татарстанның көньяк-көнчыгышы районнары арасында конкурслар үтте. Беренчесе - балалар арасында намаз уку буенча, икенчесе - мөнәҗәтләр конкурсы. Әлеге чарада Ютазы, Бөгелмә, Баулы, Лениногорск районы вәкилләре катнашты.

Конкурс тәмамланганнан соң, барлык катнашучыларга һәм җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды. Намаз уку буенча I урынны Рамил Ибраһимов, II урынны Наил Кондратьев, III урынны Муса Исламгулов яулады. Кызлар арасында намаз уку бәйгесендә II урынга Әминә Сабирова лаек дип табылды.

Мөнәҗәтләр конкурсында I урын Бөгелмәнең "Мирас" ансамбленә тапшырылды, II урын шулай ук Бөгелмә шәһәре кызы Фәния Әхмәтшинага бирелде.

### "ХАТЫН-КЫЗ БӘХЕТЕ" КУРСЛАРЫ ТӘМАМЛАНДЫ

13 декабрь көнне Казандагы Мәрҗани мәчетенең конференц-залында Мөселман яшьләре берлеге Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе ярдәме белән оештырган "Хатын-кыз бәхете" дип исемләнгән курсларның ябылу тантанасы булды.

*DUMRT.RU*

# ТЕЛ ҖИДЕ КАТ ҖИР АСТЫННАН ДА ТАБА

**18 декабрь - Гарәп теле көне. 1973 елның бу көнендә Берләшкән милләтләр оешмасындагы (ООН) Генераль ассамблея гарәп телен БМОда кулланыла торган рәсми телләрнең берсе итеп керткән. Безнең өчен гарәп теле - беренче чиратта, Изге Коръән теле. Аллаһы Тәгалә: "Коръән теле ачык итеп гарәп телендә иңдерелде" (Коръәни-Кәрим, "Шагыйрьләр" сүрәсе, 195 нче аять), - дип әйтә.**

**"Ачык итеп" дигән сүз Коръәни-Кәримнең ни өчен гарәп телендә иңдерелгәнлегенә ишарә булып тора. Гарәп теле - бай һәм матур тел. Гарәп телендә сүзләрнең синонимнары күп булу сәбәпле, Коръән сүрәләренең мәгънәләре вакытлар үткән саен тулырак ачыла бара.**

**Галимнәрнең һәр яңа ачышы, һәр яңа фәлсәфи уй-фикере нәтиҗәсендә кешелек үсеше алга омтылганлыктан, без Коръәндәге тирән мәгънәләрнең искермәвен һәм аның гел актуаль булып калуын күрәбез. Китаптагы һәр сүзнең мәгънәсенә ныграк төшенә барган саен, әйтерсең лә, ул асылташ сыман ялтырый башлый.**

**Гарәпчә белү мөселман кешесенең рухи дөньясын баета, чөнки син Коръәнне иңдерелгән телдә укый аласың. Гомумән, үзе өчен гарәп теле кебек гүзәл телдә сөйләшүче кеше дөньяны өр-яңадан ачу мөмкинлегенә ия була.**

**Татар халкы борын-борыннан гарәп телен мәгариф өлкәсендә һәм гыйбадәтләр үтәгәндә кулланып килгән. Гарәп телендә аралаша алу - кешенең укымышлы булуын сыйфатлаган. Хәзерге вакытта бик күпләр инглиз телен халыкара аралашу һәм көндәлек кулланыла торган тел буларак белә. Туган телеңне яхшы белеп, гарәп телен өйрәнергә омтылыш ясау - милли тәрбия белән сугарылган рухи хәвәслек, дип әйтергә мөмкин.**

**Моның өчен без рухи хәзинәләребезне безнең көннәргә кадәр түкми-чәчми алып килгән әби-бабаларыбызга рәхмәт белдерергә тиеш.**

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

**БЕЛЕШМӘ.** *Хәзерге вакытта гарәп телендә сөйләшүчеләрнең саны - 300 миллион тирәсе. Шуларның 240 миллионы өчен гарәп теле - ана теле, ә 50 миллионлап кеше гарәп телен икенче туган тел сыйфатында куллана. Дин өлкәсендә классик гарәп теле - Коръәни-Кәрим теле - мөселманнар тарафыннан бөтен дөньяда кулланыла. (Җир йөзендә 1,5 миллиардтан артык мөселман яши.)*

*Гарәп теле Берләшкән милләтләр оешмасындагы (ООН) Генераль ассамблея һәм башка органнарның рәсми теле итеп кертелгән. Ул барлык гарәп илләрендә, шулай ук Израиль, Эритрея, Чад, Сомали, Джибути кебек илләрдә дә дәүләт телләренең берсе буларак кулланыла.*

# ТАТАР КОНГРЕССЫ ИСӘП ТОТТЫ

***10 декабрь көнне Бөтендөнья татар конгрессының еллык җыелышы узды. Бу чарада ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе, ТР Дәүләт Советында ТР Президентының вәкаләтле вәкиле Юрий Камалтынов, ТР Президентының Тышкы элемтәләр департаменты директоры - ТР Президенты ярдәмчесе Искәндәр Мөфлиханов, ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, ТР Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү комитеты рәисе Линар Якупов һ.б. катнашты.***



Читтә яшәүче милләттәшләребез белән араларны ныгыту - Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов тарафыннан куелган иң мөһим бурычларның берсе. Россия төбәкләренә, ерак һәм якын чит илләргә эш сәфәрләре барышында Президентыбызның милләттәшләребез белән очрашып торуы күркәм гадәткә әверелде. Республика башлыгының Америка, Германия, Австралия, Польша һәм башка чит төбәк татарлары белән очрашуы, аларның тормышы, яшәеше белән кызыксынуы нәкъ менә шул хакта сөйли. Соңгы елларда Татарстанда әлеге мәсьәләләр буенча актив эш алып барыла башлады.

Көннең беренче яртысында Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының җиде комиссиясе җитәкчеләренең хисаплары тыңланды һәм резолюцияләр кабул ителде. Еллык җыенда комиссия рәисләре хисап тотты.

Киңәйтелгән утырышта чыгыш ясаучылар төбәкләрдәге татар тормышы, эш дәверендә барлыкка килгән проблемалар турында эчтәлекле фикерләрен җиткерде.

2012 елда узачак зур чаралар - Бөтендөнья татар конгрессының V съезды, V Бөтендөнья татар яшьләре форумы, федераль Сабантуйлар һ.б. турында җанлы сөйләшү булды.

***Чыганак: www.tatar-congress.org***



**Ринат Закиров, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, ТР Дәүләт Советы депутаты:**


- Менә инде егерме елдан артык татар дөньясы рухи яңарыш кичерә, халкыбыз иманга, дини асылына кайта. Шушы елларда меңләгән мәчетләр калкып чыкты, меңләгән укымышлы, гыйлемле имамнар әзерләнде. Иң куанычлысы, мәчетләргә күпләп яшьләр килә, димәк, татарда ислам диненең киләчәге өметле. Әйтергә кирәк, ислам дине һәрвакыт милләтебезнең нык, ышанычлы ныгытмасы, иң авыр, хәвефле заманнарда да татарның рухи нигезе булып торды. Бүген дә татарлар 20 миллионлы Россия мөселман өммәтенең иң зур өлешен тәшкил итә. Әлбәттә, бу безгә аеруча зур җаваплылык өсти, без илебез мөселманнары арасында үзебезнең лаеклы урыныбызны алырга тиеш. Ә моның өчен гыйлемле, фикерле, иманлы булу кирәк, монсыз тиешле абруй казанып булмый. Шөкер, бу юлда уңышларыбыз да күренә башлады инде. Мин монда беренче чиратта Казандагы Россия ислам университеты эшчәнлеге турында әйтер идем. Соңгы елларда бу уку йорты шактый әзерлекле имамнар чыгара башлады. Шуның белән бергә Россия ислам университеты илаһият гыйлемен үстерүдә дә сизелерлек уңышлар күрсәтә. Биредә ел дәвамында төрле халыкара фәнни конференцияләр уңышлы гына уза, анда мөселман илләреннән килгән галим-мөгаллимнәр күпләп катнаша. Ә бит бу безнең ислам университетының халыкара күләмдә танылуы дигән сүз. Юкка гына бит бүген Татарстанны Россия исламы витринасы дип әйтмиләр. Татарстанның ислам яңарышы юлындагы уңышларын күреп бирегә бик күп чит ил вәкилләре килә, алар безнең республика белән эшлекле элемтәләр корырга тели. Монда без татар факторын яңа сыйфатта күрәбез: Татарстандагы рухи яңарыш ислам дөньясының Россиягә ышанычын арттыра, ә шуннан чыгып, мөселман илләре Россия белән икътисади һәм сәяси хезмәттәшлекне арттыра. Бүген Татарстанда Төркия, Малайзия, Иран, гарәп илләре бизнесы республикабыз белән уртак проектларны тормышка ашыра. "Татнефть" берләшмәсе дә төрле мөселман илләрендә уртак проектлар алып бара.

Сез беләсез, соңгы елларда Үзәк диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин тырышлыгы белән Бөтендөнья татар конгрессы Изге Болгар җыеннарын уздыруны гамәлгә кертте. Быелгы Болгар җыенында Россиянең төрле төбәкләреннән килгән егерме меңнән артык кеше катнашты. Әлеге җыенның бер үзенчәлеге турында да әйтмичә булмый. Быел аны оештыруда эшләрнең күп өлешен Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев җитәкләгән "Яңарыш" фонды үз өстенә алды. Борынгы Шәһри Болгарның бүген шундый күтәрелеше күңелләребездә зур өмет уята, һичшиксез, бу масштаблы проект киләчәк буыннарда тарихи аңны үстерүгә хезмәт итәчәк.

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## *Бөгелмә мөхтәсибе:*

# "ЭШЛӘНГӘН ЭШЛӘР КҮП, ЛӘКИН ЭШЛӘНӘСЕ ЭШЛӘР ТАГЫН ДА КҮБРӘК..."





**- Мин Бөгелмә шәһәрендә туып-үскән кеше. Мәктәпне тәмамлагач, Россия ислам университетына укырга кердем. Параллель рәвештә читтән торып Мәскәү педагогика университетында белем алдым. Укып бетергәч, чит-ят җирләрдә рәхәт эзләп йөрмәдем, Аллаһның рәхмәте белән Бөгелмәгә кайтып, туган җиремдә хезмәт итә башладым. Башта мәчет имамы булып тордым, аннан соң халык тәкъдиме белән мөхтәсиб булып эшли башладым. Хәзер мин бу вазифамда җиденче елымны эшлим инде, - дип башлады үз сүзен Бөгелмә шәһәре һәм Бөгелмә районы имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйруллин.**

Әңгәмә барышында шунысы да билгеле булды: Рөстәм хәзрәт белемен арттыру өстендә дә даими шөгыльләнә икән. Эш кәгазьләре алып бару буенча ул Мәскәүдә урнашкан РФ Президенты каршындагы академия үткәргән икътисад буенча курсларда да укып кайткан. Р.Хәйруллин мөхтәсиб булып эшли башлаганчы Бөгелмә шәһәрендә ике мәчет була. Бүгенге көндә аларның саны - дүрт. Район халкының җитмеш процентын руслар тәшкил итә, шунлыктан районда мәчетләр саны да бик күп түгел: Бөгелмә мөхтәсибәтенә унөч мәчет карый. Рөстәм Миңхәйдәр улы искәртеп узганча, хәзерге вакытта Бөгелмә шәһәре читендә ике мәчет төзелеп ята икән.

***- 2011 ел, мөгаен, республикабыз елъязмасына үзенең шактый зур вакыйгалары белән кереп калыр. Дин өлкәсендә күп эшләр эшләнде. Ел ахырында сездән әңгәмә алуыбыз юкка гына түгел. Газета укучыларыбызның да беләсе килә: Татарстан башкаласыннан шактый ерак урнашкан мөхтәсибәт үтеп баручы елда ничек яшәде-эшләде икән?***

- Әлдәмдүлилләһ, 2011 елның язынннан Диния нәзарәте үзәкләшкән рәвештә эшли башлагач, эшебездә дисциплина-тәртип урнашты. Шуңа әле дә шатланып бетә алмыйбыз. Бу күптәннән кирәкле әйбер иде. Мөхтәсибәтләргә игътибар артты. Быелдан үзебездә дә яшьләр белән эшләү бүлеге булдыра алдык. Казандагы "Алтын урта" җәмгыяте кебек эшебезне оештырдык. Яшьләр белән эшләү бүлегенә Рафис хәзрәт Сәйфуллин җитәкчелек итә. Шулай ук төрмәләр белән эшлибез. Социаль проектларда да актив катнашабыз. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз карары белән уку-укыту бүлегенең эшчәнлеген активлаштырып җибәрдек. Без бу бүлеккә РИУ тәмамлаган Әмир Исмәгыйлевне җаваплы итеп куйдык. Аллаһка шөкер, программалар кайтты, тәкъдим ителгән, тикшерелгән китаплар белән генә укытабыз. Үзебезгә 350 чакрым юл үтеп, Казанга барып йөрисе юк. Үзәкләшү безнең эшебезне күпкә җиңеләйтте. Без исә хәзер үзебездәге мәчетләр белән эшләүгә зур игътибар бирә башладык. Быелдан мәчетләр каршындагы дини курсларга йөрүчеләр саны бермә-бер артты. Тәртип булмаса, халык күпләп мәчетләргә килер идемени? 2011 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан күп эшләр эшләнде. Мөфти И.Фәиз фатихасы белән газета нәшер итүебезне дәвам иттерәбез. Элек редакциягә килгән сорауларга җавапны кемнән алыйк икән дип аптырап йөри идек. Хәзер исә төбәк казыена мөрәҗәгать итәбез, ул җавап бирә. Халык исә тулы, бай эчтәлекле җавап ала. Йомгак ясап, бер генә сүз белән болай дип әйтәсе килә: эшләнгән эшләр күп, ләкин эшләнәсе эшләр тагын да күбрәк кебек. Диния нәзарәте ярдәме белән аларын да бергә башкарып чыгу әллә ни авыр булмас.

***- Сезнең мөхтәсибәттә уку-укыту эше ни рәвешле оештырылды? Булган проблемаларны ничек хәл итәсез?***

- Бөгелмә шәһәрендәге Җәмигъ мәчеттә башлангыч мәдрәсәбез эшли. Аның бинасын безгә Закировлар гаиләсе бүләк итте, коммуналь хезмәтләр өчен дә түләүләрен алар түли. Мөфтияттән алынган программа буенча анда уку-укыту эшен алып барабыз. Элек без көч-хәл белән илле кеше туплый алган булсак, быел мәдрәсә бусагасын 400 кеше атлап керде. Без әлеге уку йортына зур игътибар бирәбез. Укытучы-остазларга килгәндә, алар - мәдрәсә, югары уку йортларын тәмамлаучылар. Шәһәребезнең калган мәчетләренә дә алар атнасына бер-ике көн барып укыта. Авылларда уку-укыту эшен алып бару бераз кыенрак, чөнки имамнар олы яшьтә һәм күбесенең ярдәмчеләре дә юк. Әгәр дә алар мәчетне биш вакыт намазга ачып, вакытында азан әйтә ала икән, без әле анысы өчен дә аларга бик рәхмәтле. Авылларда дәресләр сирәк булса да бара. Безнең районда шундый практика бар: имамнар аерым расписание төзеп, уку-укыту программасына нигезләнеп, авылларга чыгып, атнасына бер тапкыр гына булса да дәрес үткәреп кайта.

***- Ә башка бүлекләрнең эшчәнлеген ничек көйләп, көчәйтеп җибәрә алдыгыз?***

- Әйткәнемчә, элек бездә дәгъват бүлеге пассив эшләп килгән иде. Хәзер бу бүлек белән Хәбир хәзрәт Ханов җитәкчелек итә. Ул Диния нәзарәте газеталары, электрон мәгълүмат чаралары белән дә актив элемтәдә тора. Мөхтәсибәтебезнең сайты бар - www.мусульмани.рф. Анда мәгълүмат даими рәвештә яңартылып, өстәлеп торыла. Казаннан йөзләгән чакрым ераклыкта яшәп, артык зур булмаган чараларны да, әлхәмдүлилләһ, кабул итеп, интернетта яктыртып киләләр. Шунысын да әйтеп үтәсем килә: эшләгән эшләребезгә дини булмаган массакүләм мәгълүмат чараларының да ышанычы артты. Элек тә журналистларны чакыра идек, тик бик киләселәре килми иде. Хәзер бу яктан бернинди дә кыенлык юк, чакырсак, киләләр. Үзебез буклетлар, брошюралар да әзерлибез.

***- Без поликонфессиональ, күпмилләтле дәүләттә яшибез. Сезнең район халкының 70 проценты ислам динендә булмаган милләт вәкилләре икәнлекне дә истә тотып, сез, мөхтәсиб буларак, бүтән дин-кардәшләребез белән бәйләнештә торуга ничек карыйсыз?***

- Әлбәттә, уңай карыйм. Бу юнәлештә дә эш алып барабыз. Без моның өчен администрациягә рәхмәтле. Православ динендәгеләр белән террорчылыкка каршы чаралар оештырабыз. Буш вакытларыбызда бер-беребез белән тәҗрибәләр уртаклашабыз. Мәчеттә үткәрелә торган зур чараларга шәһәребездәге барлык дин вәкилләрен дә чакырырга тырышабыз. Алар да безне чакыралар, барып чыгышлар ясап кайтабыз. Гомумән алганда, бер-беребезне тулыландырып, дус-тату яшәп ятабыз.

***Әңгәмәдәш –***
***Нияз САБИРҖАНОВ***

# *Татар сәхнәсендә – Мөхлисә Бубый образы*



***"Һөнәр" яшь татар режиссура фестивале вакытында театр сөючеләр хөкеменә Илгиз Зәйниев Ркаил Зәйдулланың "Үлеп яратты" дигән әсәрен сәхнәләштерде. Моңарчы Илгиз талантлы һәм өметле яшь драматург икәнен тамашачы алдында күп тапкырлар исбатлаган иде инде, дип яза www.intertat.ru сайты.***

Быелгы "Һөнәр" фестивалендә егет үзен драма режиссёры буларак сынап карады. (Әлбәттә, Илгизне төрле чараларда режиссёр сыйфатында күргәләгән бар иде.) Ләкин "Үлеп яратты" спектаклендә егетне фикерле режиссёр буларак күрдек. Спектакль тулаем җылы тәэсир калдыра, милли горурлык хисенә кагылып, селкетеп куя. Тамашаның сценографиясе дә уңышлы хәл ителгән: арттагы декорацияләрдә шәүлә театры элементлары белән тулыландыру, гаять үтемле музыка, училище студентлары башкаруында борынгы татар халык җырларының берничә тавышка яңгыравы (хормейстер Марат Яхъяев), алгы планда саран гына реквизит белән дә куәтле актёрлар ансамбле туплау нәтиҗәсендә бик камил һәм отышлы куелыш килеп чыккан.

Спектакльнең героинясы Мөхлисә Бубый - тарихта беренче татар мөгаллимәләреннән санала. Бу шәхес Россия мөселман дөньясында хатын-кызлар өчен иң беренче мәдрәсәгә нигез салган һәм беренче хатын-кыз казый буларак та мәгълүм. Ул бар тормышын яшь буынга аң-белем бирүгә багышлаган шәхес. "Халык дошманы" дигән яла ягылып төрмәдә җәфаланса да, тоткан кыйбласын югалтмый, иманына тугры кала алган олуг зат.

"Халкыбыз, ниһаять, тамырларына, милли үзаңына һәм иманына кире кайткан бу чорда үз туган телендә гомуми һәм дини белем алуга мохтаҗ. Нәкъ шушы, бүгенге көн өчен әһәмиятле мәсьәлә Ркаил Зәйдулла иҗат иткән "Үлеп яратты" пьесасының төп идеясен тәшкил итә. Сталин чорында мәдәниятебез коточкыч зур югалтулар кичерә: йөзләгән, меңләгән татар зыялылары, әдәбият, фән вәкилләре, җәмәгать эшлекләре һәм дин әһелләре юк ителә, ә аларның хезмәтләре тыела. Үзләрен аямыйча халкыбызга хезмәт иткән бу шәхесләрнең исемнәре, эшләре һәм фаҗигале язмышлары бүген тарих төпкелләреннән күтәрелеп тормышыбызга кайта бара һәм гүя кисәтү булып яңгырый..." - дип яза Г.Камал театрының рәсми сайты.

Мөхлисә Бубыйны Татарстанның халык артисты Дания Нурлы башкарды. Дания ханым - тамашачы мәхәббәте яулаган мөхтәрәм артистларның берсе. Аны без характерлы рольләрдә дә, калку-кодрәтле образларда да күрергә күнеккән. Яңа премьерада артист кабатланмас уены белән күңелләрдә уелып калды. Актриса күрәләтә тирән, күкрәк тавышы белән сөйли, шунлыктан аның фикере саллы һәм ышандыргыч. Дания ханым чып-чын мөгаллимәне, иманлы, зыялы татар хатынын гәүдәләндерүгә ирешкән. Артистның баш ияргә ап-ак шәл бөркәнеп чыгуында да әнә шул фикер ята иде сыман.

Мөхлисәнең асрауга алган кызы - Нәҗияне театрның тагы бер талантлы артисты Миләүшә Шәйхетдинова башкарды. Миләүшә нинди образга алынса да хасиятле, үзенә генә хас алымнар белән башкарырга сәләтле, интеллектуаль актёрлардан саналырга хаклы.

Яшь актёр Эмиль Талиповның Корбанов образы да уңышлы һәм ышандыргыч килеп чыккан. Аның кеше асылын ачыкларга теләве, замана борылышларында эчке умырткаңны саклап кала алу мөмкинлеген эзләве, шулар җирлегендә Мөхлисә Бубыйга соклануы шактый тулы һәм экспрессив буяулар белән эшләнелгән иде. Аның коллегасы Дәүләтов - Илдус Габдрахмановка: "Ул синең үзеңне төрек шпионы ясарга мөмкин!" - диюе нигезсез түгел. Корбанов кеше холкын нык өйрәнгән. Аның кушаматы да "колун". Ләкин Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен, Аның кодрәтен һәрнәрсәдә күрә белгән мөслимәнең иман ныклыгы, какшамас тәкъвалыгы система итеген ялаучы чекистны да уйланырга мәҗбүр иткән!

Алсу Каюмовага бу спектакльдә Бубыйның шәкерте булып, хәзер аның белән бергә төрмәгә эләккән комиссар кыз Галия ролен тапшырганнар. Алсу һәр образын ярата. Аның эчкерсез, тирән уенында органика да, драматизм да җитәрлек. Яңа җәмгыять төзүгә бар калебе белән инанган (һәм шуның белән ялгышкан) Галия кызганыч та, күркәм дә. Нәкъ тормыштагыча, җәмәгать! Актёр өчен бу зур мәртәбә дип саналырга хаклы, минемчә. Афәрин, Алсу!

Ркаил Зәйдулла Ротмистр (Айрат Арсланов) авызына хәзерге заман белән кисешкән чынбарлык мизгелләрен "салган". Бәрәкалла, ничә ел узса да, ил чынбарлыгы да әллә ни үзгәрмәгән икән ич, бары тик машиналар арткан да, тормыш технологияләре генә алга киткән. Ркаилның бу әсәре милли драматургиядә уңышлы яңалык дип аталырга хаклы. Хәер, Тукай премиясе лауреатыннан без башка нәрсә өмет итәргә хаклы да түгелдер. Әлеге "Үлеп яратты" әсәре дә драматургның "Яңа татар пьесасы - 2010" бәйгесендә Татарстан мәдәниятенең махсус бүләгенә ия булган иде.

Бәйләнер урыннарга килгәндә, пьесаның исеме "Үлеп яратты" уңышлы ук түгел кебек. Әсәр эчтәлеген белмәгән гавам халкы аны төрлечә "вариацияли". Әсәрдән җырлап тора торган, саф татарча, күркәм яңгырашлы берәр гыйбарә, сүз я җөмлә дә табып булган булыр иде, мөгаен.

***Мөршидә КЫЯМОВА***
***Шамил АБДЮШЕВ фотосы***

# Ислам – сәламәт яшәү чыганагы

## (Ата-аналар һәм яшүсмерләр белән әңгәмә)

***Хәзерге заман гаҗәеп катлаулы, өстәвенә әле бик каршылыклы да. Урлашу, кеше үтерү, көчләүләр, эчкечеләр, наркоманнар саны арта бара. Иң хафага салганы - рухи һәм физик сәламәтлекнең кими баруы; бу, барыннан да элек, балалар, үсмерләр сәламәтлегенә кагыла. Бигрәк тә балаларның сәламәтлеге аянычь хәлдә. Россиядә ел саен күп меңнәрчә бала үлә. Балаларның 34 проценты - сулыш органнары, 52 проценты - ашказаны, 21 проценты нерв системасы чиреннән интегә. 17 мең балада - шикәр диабеты диагнозы, 720 мең бала - инвалид. Мәктәп балаларының бары тик 9-10 проценты гына сау-сәламәт исәпләнә. Сәламәтлек саклау буенча дәүләткүләм әһәмиятле документлар кабул ителә, программалар эшләнә, дистәләгән спорт корылмалары, стадионнар төзелә. Ләкин мәктәп тәмамлаган яшүсмер егетләрнең 70-80 проценты хәрби хезмәткә яраксыз. Яшьләр баштанаяк тәмәке төтененә чумган, аракысыра диңгезендә йөзә, фахишәлек белән шөгыльләнә, наркоманга әверелә. Бу күңелсез саннарга һәм чирләргә яңалары - төрле психик авырулар һәм суицидлар өстәлде.***


Кешенең сәламәтлегенә һәм рухи кыйммәтләр хәзергәчә шулай җимерелеп барса, милләт буларак сакланып калырбызмы, сәламәт җәмгыять төзи алырбызмы? Дәүләт тарафыннан кабул ителгән сәламәтлек программаларының фәнни-методик кыйммәтен танымый мөмкин түгел. Ләкин андый программалар төзеп, документлар, карарлар кабул итеп, планнар алып кына сәламәт яшәү рәвешенә ирешә алмавыбыз көннән-көн ачыграк күренә бара. Балалар күп туа дип шапырынсак та, илдә демография кризисы дәвам итә. "Росстат" мәгълүматлары буенча, соңгы бер ел эчендә Россиядә халык 363,5 меңгә кимегән. Россия кешенең гомер озынлыгы буенча дөньяда 158нче урында тора. (Бездән артта Африка илләре генә.)

Әйләнә-тирәнең тискәре тәэсире, җәмгыятьнең икътисадый хәле кискенләшү сәламәтлек начарлануның төп сәбәпләре булып тора. Әмма, болар белән беррәттән, сәламәтләндерү чараларының нидән гыйбарәт булуын белеп бетермәү дә сәламәтлеккә зур зыян китерергә мөмкин.

Сау-сәламәт шәхес булу өчен, организмның бөтен мөмкинлекләрен дә файдалана алырлык дәрәҗәдә белем һәм күнекмәләргә ия булу мөһим. Шундый мөмкинлек - сәламәт яшәүгә бөтен тулылыгы белән өйрәткән ислам тәгълиматы. Әгәр ислам кануннары үсеп килүче буынга сәламәтлек чыганагы буларак тәкъдим ителсә һәм аңлатылса, Коръән аятьләренә ышандырырлык төпле дәлилләр күрсәтелсә, мәктәпләрдә тәрбиянең яңа формалары туар, сәламәт яшәү рәвеше турында яңа фикерләр, күзаллаулар барлыкка килер, дип саныйм.

Еш кына исламны намаз уку, ураза тоту кебек гыйбадәтләр белән тиңләштерәләр. Билгеле, динебезнең баганасы булган бу гамәлләрдән башка кешене мөселман дип исәпләп булмый. Ләкин динне тормышка беркетелгән бер өстәмә әйбер рәвешендә генә кабул итәргә ярамый. Ислам һәртөрле дәүләт программаларыннан өстен, чөнки анда ышану, инану бар, Аллаһтан курку бар.

"Кешеләр ике төрле нигъмәтнең кадерен белми, - ди пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв). - Берсе - вакыт, икенчесе - сәламәтлек". Аллаһы Тәгалә кешегә күркәм тәнен, сизгер җанын, акылын һәм иң зур нигъмәт булган - саулыгын да биргән, биреп кенә калмаган, аны саклау кагыйдәләрен пәйгамбәребез (сгв) аркылы ирештергән. Ул үзенең хак сүзе булган Коръәндә сәламәтлеккә зыян китерүче һәрбер нәрсәне тыя һәм кешенең саулыгын ныгытуга юнәлдерелгән гамәлләргә этәрә. Ислам һәм сәламәтлек - тамырдаш сүзләр.



Ислам сүзе "әсләмә" дигән фигыльдән алынган, ул буйсыну дигәнне аңлата, сәламәтлек сүзе дә шушы фигыльдән ясалган. Аллаһы Тәгаләгә буйсынмыйча сәламәт булып булмый. Кыямәт көнендә кешедән соралачак беренче нигъмәт - сәламәтлеге булачак. Аңа: "Мин синең тәнеңне сәламәт итмәдеммени?" - диеләчәк. Сәламәтлек дигәндә тәндә авыруларның юклыгы гына күздә тотылмый. Исламча сәламәтлек - ул рух тынычлыгы һәм тормышта бар яктан иминлек дигән сүз. Исламда җан тынычлыгы тән сәламәтлеге белән бергә үрелеп бара, ә болардан башка гаилә, җәмгыять, дөнья һәм ахирәт сихәтлеге була алмый. Безнең җәмгыятьтә исә бүген сәламәтлек тәндәге төрле авыруларны дәвалауга гына кайтып кала. Ә ислам дине сәламәтлекне саклауны дөрес туклануда, хезмәт итүдә, киенүдә, йоклауда, ял итүдә, җенси мөнәсәбәтләрдә, Аллаһы Тәгалә кушканнарны төгәл үтәп яшәүдә күрә. Сәламәтлекнең нигезе - дөрес туклану. Пәйгамбәребез (сгв) бу турыда менә нәрсәләр әйткән:

- Озак ашалмыйча калган ризыкны ашамагыз.
- Ризыкны бик кайнар яки салкын булганда ашамагыз.
- Кулларыгызны ашау алдыннан һәм ашаганнан соң юыгыз.
- Артык туйганчы ашамагыз.
- Ашаган арада суны күп эчмәгез.
- Ялгыз гына ашамагыз.
- Алҗыган, арыган булсагыз, татлы ризык ашап куегыз.
- Ай эчендә бер көн булса да ураза тотыгыз, тәнегезне ял иттерегез.

Шәригатебез буенча кеше өстәл яныннан тамагы туймыйча торырга тиеш. Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Адәм баласы тутыра торган капчыклар арасында корсактан да начар капчык юк. Адәм баласының дөньяда торуына бер йотым су җитә. Әгәр дә ашау зарур булса, ягъни тиеш булса, ул карынын өчкә бүлсен: бер өлешенә - аш, икенче өлешенә - су, өченче өлешенә - һава". "Кайсы дәва яхшырак?" - дигән сорауга табиблар да: "Ашыйсың килеп тә, ашаудан туктау", - дип җавап бирә. "Пәрдә" сүрәсенең 31 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: "Ашагыз, эчегез, әмма исраф кылмагыз, чынлыкта Аллаһ исраф кылучыларны яратмый", - ди. Шәригать белгечләре фикеренчә, бу ике җөмләдә кешенең сәламәтлеген саклау өчен кирәкле бөтен нәрсә хакында да әйтелгән. Туйганнан соң ашау - исраф. Динебездә һәрбер исраф - хәрам, тыелган гамәл. Күп ашау акылга, әдәпкә дә кимчелек китерә. Кешенең акылы кими, холкы бозыла, юк-бар нәрсәләрдән курка башлый. Пәйгамбәребез (сгв) бер хәдисендә: "Өммәтем өчен куркынычның да куркынычы: корсакның чамасыз зурлыгы, йокының озаккарак сузылуы, ялкаулык һәм иманның зәгыйфьлеге", - ди.

Ризык аксымга, витаминнарга, минералларга я, киресенчә, токсинга, химикатларга бай булырга мөмкин. Ризык файдалы булсын өчен, ул чиста булырга тиеш. Коръәндә бу күп тапкыр кабатлана. "Аллаһ сезнең өчен хәләл иткән пакь ризыкларны ашагыз һәм үзегез ышанган Аллаһыдан куркыгыз", - ди. ("Аш яулыгы" сүрәсе, 88 нче аять).

Революциягә кадәр татар халкының туклануы югары культуралы булган. Бигрәк тә авылларда җанга да, тәнгә дә зыянлы әйберләр ашамаганнар. Революциядән соң хәл үзгәрә. Динне бетерү нәтиҗәсендә хәләл ризык урынына хәрам көчәя. Социализм вакытында татарларның өстәл түренә аракы белән дуңгыз казылыгы менеп утыра. Нәтиҗәдә тәне хәрамнан җыелган сәрхүшләр кавеме барлыкка килә.

Алкоголь куллануның зарары турында күп сөйләп тору мәслихәт түгелдер, чөнки без аны көн дә үзебезнең күзләребез белән күреп торабыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Исертә торган эчемлекләрдән сакланыгыз. Монда бернинди дә шик юк, ул гөнаһларның һәм золымнарның чыганагы", - дигән. Хәмернең хәрамлыгы - аның составында түгел, ә бозыклык чыганагы булуында.

"Әгәр берәү хәмер эчсә, иманы аны ташлап чыгар", - дигән хәдис бар. Димәк, аракы эчкән кеше - башка кешеләр өчен бәла-каза, куркыныч чыганагы. Исерек хәтта үзенең әти-әнисенә, балаларына карата да җинаять эшләргә мөмкин. Шуңа күрә ризыкның хәләллеген кайгырту ул - киләчәк буынны кайгырту дигән сүз. Сәламәт булсын өчен кеше дөрес тукланырга тиеш, дидек. Ләкин кеше аз хәрәкәтләнсә, ризык тулысынча үзләштерелми, организм шлаклар белән тула. Аз хәрәкәтләнү бүген заман чиренә әйләнеп бара. Халыкта: "Хәрәкәттә - бәрәкәт", дигән әйтем бар. Галимнәр: "Физик күнегүләр кешедә стресс халәтен юкка чыгара, артык авырлыктан коткара, йөрәк-кан тамырлары, шикәр авыруларын киметү чарасы булып тора", - ди. Бүгенге мәктәп балаларының күбесе, хәрәкәт җитмәү аркасында, остеохондроз, артропатия, сколиоз, яссы табанлылык, симерү кебек чирләрдән җәфа чигә. Мәктәптә физкультура дәресләре санын арттырып карыйлар, сәламәтлек сәгатьләре кертәләр, дәрес саен физкультминуткалар үткәрәләр, күптөрле спорт секцияләре эшли - әмма сизелерлек нәтиҗә юк. Галимнәрнең соңгы тикшеренүләре "Сәламәтлекнең нигезендә намаз уку тора", дигән фикергә этәрә. Баш мие эшчәнлеген җиргә иелү нәтиҗәсендә яхшыртырга була. Күп мәртәбә иелү, ягъни Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән сәҗдә кылу нәтиҗәсендә баш миенең кан тамырлары ныгый һәм тыгызлана. "Сәҗдәгә төшү генә дә йөздән артык чирдән арынырга ярдәм итә", дип белдерә гомумсәламәтләндерү үзәкләре.

Кеше организмында 360 буын бар. Намаз вакытында аларның барысы да хәрәкәткә килә. Билгеле, физик активлыкны яшь буын өчен намаз белән генә чикләп кую дөрес булмас иде. Диндә башка төр физик эшчәнлеккә дә зур игътибар бирелә. Мәсәлән: "Берегезнең бау алып тауга барып утын җыюы, шуны китереп сатуы һәм шуннан сәдака бирүе кешеләрдән соранып йөрүгә караганда хәерлерәктер".

(Ахыры 4 нче биттә.)

# Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен

*Тәрбиядә бүген төп ике фактор калды. Дин һәм хезмәт. Балтач районы әхлак мөгаллимәләре мәктәпләрдә ундүрт ел эшләү дәверендә моны күптән аңлады инде. Һәм алар бөтен көч-сәләтләрен кызганмыйча балаларны ислам кануннары буенча тәрбияләргә омтыла. "Җитәкчеләре, рухи әйдәп баручысы ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең баш казые булгач, аларга җиңел шул!" - диючеләр булыр. Юк шул, шактый киртәләрне җиңәргә, максатка ирешүдә рухи пакьлекне яклап көрәшкәндә күп көч түгәргә туры килде. Җәлил хәзрәт тә район мөхтәсибәтен оештыру өчен тазалыгын, вакытын, көч-сәләтен эшкә җигеп җаны-тәне белән тырышып йөрүче гап-гади мулла иде. "Дәресләрдә Аллаһтан "а" хәрефе, диннән "д" хәрефе булмасын!" - дигән тыюларны да еш ишеттек.*

*Ә менә 2011-2012 нче уку елын ышаныч һәм тыныч күңел белән башладык. Чөнки дәүләт структуралары мәктәпләрдә диннәр тарихын укыту мәсьәләсен куйды.*

*Дөньяви белемне дини белем белән ныгыту балага тормышны, яшәешне танып белүне күпкә җиңеләйтә. Күп кенә Европа илләрендә, әйтик, Швейцария, Австрия, Алманиядә дин сабаклары бала күңеленә бик кечкенәдән - башлангыч сыйныфлардан ук сеңдерелә.*

*Уку елы алдыннан мөгаллим-мөгаллимәләр җыелып киңәшәләр, проблемаларны уртага салып сөйләшәләр. Әхлак - социаль-педагогик түгәрәк дип исәпләнсә дә, без аны үзебезчә дәресләр дип йөртәбез. Ачык дәресләр елына дүрт-биш мәртәбә үткәрелеп, анда мәктәп җирлегендәге абыстайлар, имамнар һәм республикадан кунаклар чакырыла. Ягъни, күрсәткән ачык дәресләр мөгаллим-мөгаллимәләрнең республикакүләм эшләре булып санала һәм бу гаять зур җаваплылык. Һәр ачык чара күрсәтүче дәресләрендә республиканың теләсә-кайсы төбәгеннән килүче кулланма итеп алырлык мәгълүмат бирергә, үзенчәлекле нанотехнологияләр кулланырга тиеш. Һәм мөгаллимнәребез нәкъ шулай эшли дә. Үткәрелгән ачык дәрес эшкәртмәләре тупланып, махсус җыентыкларда басыла. Шундый җыентыкларның икесе "Иман" нәшриятында дөнья күрде.*

*"Әхлак дәресләре" җыентыгында район әхлак мөгаллимнәренең иң яхшы дәрес эшкәртмәләре, ә "Әдәп орлыклары" дип аталган җыентыкта Гөлфәния Фазлыеваның бакча балалары өчен әңгәмә, кичә үрнәкләре туплап бирелгән.*

*Бу уку елында беренче ачык дәрес һәм ачык чараны Кенә төп мәктәбендә Кадрия Фәрит кызы Фәйзрахманова үткәрде.*

*Темасы үтә актуаль - "Кеше булып яшәргә нәрсә кирәк кешегә?" дип атала иде.*

*Девизы: "Кешене кеше иткән бер нәрсә - Кешелеклелек".*

*Дәрес уңай психологик халәт тудыру - "Комплиментлар" уены белән башланып китте. Иң элек грамматик биремнәрне үтәделәр: гарәп язуында сузык авазларны тартыклар янында күрсәтү кагыйдәләрен өйрәнделәр.*

*Аннан Фәнис Яруллинның "Йолдыз тапкан кыз" әсәрендә әхлак, кешелеклелек төшенчәсе турында кызыклы әңгәмә, бәхәс, ачышлар турында сөйләшү булды...*

*Әдәби әсәрдә бирелгән фикерләр ислам кануннары белән нигезләнде. Әйтик, тәүбә - ул җиде хәлдән җиде хәлгә күчү.*

*Нәтиҗә: "Аллаһ кушканнарны үтәп, ул тыйганнардан тыелып яшәсәк, ниятебез изгелектә булса, бәхеткә ирешербез".*

*Халык мәкальләре белән пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләре арасында мәгънәви уртаклык бар. Мөгаллимә әдәбият, әхлак, гарәп грамматикасы дәресләрен комплексны алып барды.*

*"Көз һәм хезмәт бәйрәме" исеме белән үткәрелгән сыйныфтан тыш чара хезмәт аша хөрмәткә ирешү, өлкәннәребезгә ихтирам тәрбияләү максатын тормышка ашырды. Кичәгә хуҗалыкның иң мөхтәрәм игенчеләре - механизаторлар чакырылган. Арада сугыш һәм сугыштан соңгы елларда ундүрт ел корыч атны иярләгән Мөбәширә апа да бар.*

*Фикер алышулар вакытында район методистлар берлеге җитәкчесе Гадения ханым Гарипова, әхлак мөгаллимнәре җитәкчесе Илзирә Мортазина, Балтач мәчете имамы Рамил хәзрәт Бикбаев, мөгаллим-мөгаллимәләр чараларны югары бәяләп кенә калмыйча, кимчелекләрне күрсәтеп, киңәш-тәкъдимнәрен дә җиткерде. Мөгаллимнәр семинардан үзләре өчен бай мәгълүмат алып, тәҗрибә туплап, зур канәгатьләнү белән таралышты.*

**Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА, Балтач районы Шубан төп мәктәбенең югары категорияле әхлак мөгаллимәсе, хезмәт ветераны**

# ТАТАР КОНГРЕССЫ ИСӘП ТОТТЫ

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Әйе, соңгы ике дистә ел эчендәге татар күтәрелеше бик күп юнәлешләрдә бара, һәм моны Россиядә дә, дөньяда да күрәләр. Ә әйтеп үткән Болгар проекты шушы күтәрелешнең иң күркәм чагылышыдыр, мөгаен.

Инде традициягә әверелеп барган Бөтенроссия имамнар форумы да илкүләм яңгыраш алды. Дин өлкәсендә җыелган күп санлы проблемаларны хәл итүдә бу җыенның әһәмияте искиткеч зур. Узган ике җыенда да Татарстан Президентының катнашуы республика җитәкчелегенең динебезгә карата никадәр игътибарлы булуын күрсәтә. Дин өлкәсе милләтебезне саклау эшендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе. Шуңа да без читтән күзәтеп торучы сыйфатында гына калырга тиеш түгел, ә үзебезгә дини тормышның эчендә кайнарга кирәк. Халкыбызның гасырлардан килгән гореф-гадәтләреннән читләшергә ярамый, монда дин кардәшләр белән бергә төрле чараларда, Корбан ашларында, Ураза гаетләрендә актив катнашу да бик мөһим.

**(Р.З.Закировның РФ һәм БДБ илләрендәге татар иҗтимагый оешмалары җитәкчеләре катнашында Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының 2011 ел эш нәтиҗәләре буенча киңәйтелгән утырышында ясаган чыгышыннан)**

# Ислам - сәламәт яшәү чыганагы

(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)

Рәсүлебез бу хәдистә кул көче белән эшләп ашарга чакыра. Үз хезмәтең белән гаиләңне туйдыру - иң күркәм эшләрнең берсе. Дөньяда иң ләззәтле икмәк - адәм баласының үз кәсебе, үз кул көче белән табылган һәм маңгай тирләрен агызып кулга кергән икмәктер. Хезмәт белән бергә ял итү - урман-болыннарга чыгу, төрле уеннар уйнау - Аллаһы Тәгаләгә сөекле булган гамәлләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Күңел ачыгыз һәм уйнагыз, минем диндәшләремнең кәефе начар булу миңа бер дә ошамый", - дигән. Физик күнегүләр ярдәмендә кеше стресстан, симерүдән котыла, иммунитетын ныгыта.

Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итеп, гомер буе биш вакыт намазын укыган кешенең битләре - нурлы, сыннары - туры, зиһеннәре яхшы була, чөнки актив физик тормыш белән яшәү балалар тәненең барлык өлешләрен гармоник рәвештә үстерә һәм олыгайгач та яшьлек сыйфатларын саклау мөмкинлеген бирә. Намаз - кешенең күңелен тулысынча пакьләндерүче гамәл булып тора, калебен йомшарта.


Бүгенге мәктәп балаларының сәламәтлеген саклауда киемнең әһәмияте бөтенләй исәпкә алынмый. Исламда ашау-эчүдәге кебек хәләл һәм хәрам киемнәр бар. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: "И адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар өчен һәм сезне матурлау өчен", - ди. ("Пәрдә" сүрәсе, 26 нчы аять). Башка яулык бәйләп йөрүне генә алыйк. Безнең җәмгыятьтә ул негатив күренеш кебек санала. Әмма яулык ул - профилактика һәм дәвалану чарасы да. Баш киеме киеп яки яулык бәйләп йөрү баш авыруларыннан, суык тиюдән, чәч коелудан саклый. Аллаһыга ышанып, башны ябып йөрү кешене төрле чирдән дарусыз дәвалый. Мәктәпләребездәге кыз балаларны күрегез: аларның күбесе ярымшәрә: үтә күренмәле кием-салым, кыска итәкләр, кысып торган джинсылар, кендек ачык, чәч-баш тузган. Бүгенге кызларны гаурәтләрен каплап киендерү мөмкин түгел. Чөнки алар үзләре дә, әтиәниләр дә шәрә йөрүнең гөнаһ икәнен белми. Өстәвенә, болай йөреп, күрә торып үз сәламәтлекләрен бетерәләр. Соңгы фәнни тикшеренүләр кыска итәк киеп йөрүче хатын-кызлар арасында яман шеш авыруларының еш очравын исбат итте. Джинсы чалбарлар кию аркасында корсак куышлыгында урнашкан әгъзаларның (аналык, сидек куыгы, туры эчәк) даими рәвештә кысылуы сәбәпле, бу әгъзаларда веноз басымы күтәрелә, бу хәл ялкынсынуга, хәтта яман шеш авырулары барлыкка килүгә сәбәп булып тора.

Сәламәтлек турында сөйләгәндә ураза турында әйтми калу мөмкин түгел. Чөнки хәзер киң таралган авыруларның кайберләрен ураза тоту белән дәвалыйлар. Ураза - ихтыяри ач торуның иң яхшы үрнәге. Ул - сәламәтлекне саклау өчен генә түгел, ә бәлки авыруларны дәвалау өчен дә файдалы гамәл. Ураза тоткан кешенең тәкъвалыгы ныгый. Ураза нәфесне чикли, кешенең күңеле сафлана, сабырлыгы арта. Уразаның асыл мәгънәсе - һәм рухи, һәм җисми яктан пакьләнү. Ач бәдәндә йөрәк бер чама белән эшли, акыл тынычлана, күз үткерләнә! Пәйгамбәребез (сгв): "Ураза тотыгыз, сәламәт булырсыз!" - дип, юкка гына әйтмәгән шул.

Бүгенге икътисадый тотрыксызлык, җәмгыятьтәге һәм мәктәптәге реформалар кешене даими психик киеренкелектә, стресс халәтендә яшәтә. Ә стресслар бик күп чирнең килеп чыгуына сәбәп булып тора. Стресс яман шеш күзәнәкләре үсүенә ярдәм итә. Алай гына да түгел, стресс йөрәк-кан тамыры авыруларына, диабет, инсультка китерә. Шуңа күрә пәйгамбәребез (сгв): "Артыгын борчылу - гөнаһ!" - дигән хәдисен истән чыгармаска кирәк. Ни өченме? Азрак борчылу - битараф булмау. Кайгы-хәсрәткә бирелү - аерым бер рухи өлеш кенә. Чамасыз шатлану, куану да чирләр тудырырга сәләтле, ягъни нинди генә стресс булмасын, ул кеше сәламәтлеге өчен зыянлы. Шуңа күрә һәрчак үзеңнең психикаңны тотрыклы тотарга өйрәнергә кирәк. Моңа ирешүдә Ислам дине ярдәм итә.

**_Фәрит ВАФИН,_**
**_Арча районы Яңа Кенәр интернат-мәктәбе укытучысы_**

# ҖИЛКӘННӘР ҖИЛДӘ СЫНАЛА...



Узган атнаның җомга иртәсендә таралып өлгергән хәбәр берәүне дә игътибарсыз калдырмагандыр, мөгаен. Аны һәр кеше үзенчә кабул итте. Берәүләр: "Күп азапланды инде", - дисә, икенчеләре исә чын күңелдән кайгырды. Бу - Г.Тукай һәм М.Җәлил исемендәге премияләр лауреаты, күп сандагы шигырьләр, җырлар, лирик һәм юмористик хикәяләр авторы Фәнис Яруллинның якты дөньядан китү хәбәре иде. Аның язмышын белмәгән, ишетмәгән, әсәрләре белән таныш булмаган кешеләр сирәктер. Югарыга карап-фикер йөрт, түбәнгә карап шөкер ит, ди безнең халык. Миңа калса, бүгенге көндә без нәкъ менә шушы мәкальне тормышыбызда кулланмыйбыз. Бүгенге көндә популяр булган www.vkontakte.ru сайтындагы статусларның күбесен укыганда чәчләр үрә тора. Тормыштан зарлану, аның бары караңгы якларын гына күрү, яшәү мәгънәсен таба алмау белән шыплап тулган алар. Мондый статусларны Фәнис ага укыса, ни дип әйтер иде микән? Аларны язган кешеләр нигә Фәнис Яруллин һәм аңа охшаш язмышлы кешеләрне исләренә төшерми икән? Фәнис аганың тормышына карап без күпме гыйбрәт ала алабыз бит! Шундый сынауга дучар булып та сынмаган, сыгылмаган кешеләрнең язмышын белү безгә бик күп көч өсти, егылган вакытларда торып алга таба атларга мәҗбүр итә. Коръәндә дә бит кешеләр уйлансын, фикер йөртсен өчен, безгә кадәр яшәгән халыклар турында мисаллар күп китерелә. Без дә үз арабыздагы гыйбрәт алырлык язмышларны белергә тиешбез. Күпме сау-сәламәт, хәлле кешеләр үзләренә кул салуга кадәр барып җитә. Беребез дә онытмыйк: бу дөньяга без сынау өчен килгәнбез. Һәр адәм баласына Аллаһы Тәгалә сынауның ул кеше күтәрә алырлыгын гына бирә. Кемнеңдер сәламәтлеген, байлыгын, баласын ала, кемгәдер сәламәтлек, байлык, бала бирә. Әйе, болар барысы да сынау. Без дә бу имтиханнарны Аллаһы Тәгалә риза булырлык итеп тапшырсак иде. Депрессиягә бирелү XXI гасырның иң таралган афәтләренең берсе. Әмма аяк-кулларыбыз исән-сау, күзләребез күреп торганда, күңел төшенкелегенә бирелү турында нинди сүз була ала? Җир йөзендә меңләгән кеше бер генә адым ясау, бер генә тапкыр булса да якты дөньяны күрү турында хыяллана. Ә без... Һәммәбезгә дә чираттагы зарыбызны кешеләргә сөйләр алдыннан шулар турында фикер йөртергә өйрәнергә иде. Яшь вакытыннан ук урын җир өстенә калган Фәнис аганың авыр вакытлары бик күп булган. Әмма аңа карап ул бирешмәгән, карандашны авызына кабып, өр-яңадан язарга өйрәнгән. Аның әсәрләре арасында уйланырга һәм шундый авыр язмышка ия булган хәлдә дә тормышка юмор аша карап, укучыларны елмайта торганнары да бар.

Ф.Яруллинның югалып калмавында хәләл җефетенең роле зур. Иң авыр вакытларында янында булып, яшәргә көч биреп торган Нурсөя ханым Ходай Тәгалә тарафыннан аңа ясалган зур бүләктер, мөгаен. Ирләренең һәр адымыннан зарланырга яратучы ханымнарны аның белән очраштырып бер сөйләштерергә иде.

Фәнис ага бүген безнең арабызда юк, әмма аның исеме, әсәрләре күп еллар дәвамында һәркайсыбызның күңелендә саклаэныр.

Якты дөньядагы һәр минутның исәбен, якыннарыбызның кадерен белеп яшәсәк иде.

**_Ландыш ИБРАҺИМОВА_**

Рүзәл ЮСУПОВ:

# "Татар халкының рухы нык"

**_Сораугa Казан (Идел буе) федераль университетындагы Филология һәм сәнгать институты профессоры, филология фәннәре докторы, Татарстан фәннәр академиясе академигы Рүзәл Юсупов җавап бирә:_**



- Бу бик тә әһәмиятле һәм киңкырлы төшенчә. Аны күпьяклап карарга мөмкин. Дин белән янәшә караганда, ул - кешенең иманы, аның дөньяга (эшкә, җәмгыятькә һ.б.) карашы. Адәм баласының максаты да аның рухында чагыла. Ул бу тормышка нинди максатлар куеп яши? Нәрсә тели ул, аның тормышка булган ниятләре нидә? Рух (кешенең яшәвенең тамыры-нигезе) сәламәт булса, эш тә, яшәү дә, тормыш та әйбәт була. Барыбер, алга таба барыш була. Ә рух начар, бозык, какшаган булса (ныклы булмаса), ул вакытта бу барлык атрибут-өлкәләрдә дә чагылыш таба. Татар халкының рухы, гомумән алганда, моңарчы нык булды. Аның иманы бар иде. Ул тарихыбыз - татарларның ислам динендә булуы белән тыгыз бәйләнгән. Совет чорында динне бетерергә тырышсалар да, ул безнең рухыбызда сакланып калды. Кешенең рухы гыйбадәтханәләргә йөрү белән генә билгеләнми. Ул аның күңелендә була. Ислам дине һәрвакытта да изгегә, яхшылыкка өйрәтә, аң-белемгә чакыра, әхлаклылык, яхшы сыйфатлар тәрбияләргә тырыша. Халкыбызның рухы көчле булып калуга шулар бик нык ярдәм итте. Соңгы вакытта дингә караш яхшы якка үзгәрде. Дин үсешенә дәүләтнең дә ярдәме зур. Ә бит элек киресенчә - зыян китерәләр, каршылыклар тудыралар иде. Хәзер кешеләргә дин тотарга ярдәм итәләр. Болар барысы да рухның нык булуына ярдәм итә. Гомумән алганда, татар кешесенең рухы әлегә ныклы. Урта буын вәкилләрендә дә менә бу рух сынмаган.

Кешенең рухы - ул дин генә түгел, ул традицияләр, йолалар, гореф-гадәтләр дә. Болар һәммәсе дә ата-бабадан бирелә, буыннан-буынга күчеп бара. Татарларда яхшылыкка омтылу, әдәп-әхлак нормалары, иманлы, изге күңелле, яхшы, игелекле булу кебек сыйфатлар башка халыкларга караганда күбрәк сакланган. Кыенлыклар булса да, киләчәккә өмет зур. Россия җәмгыятендә хәзер авыр чор. Икътисади кризиска караганда рухи кризис көчлерәк. Җәмгыять алга бик авыр темплар белән бара. Авырлыклар кычкырып тормаса да, моны анализ ясый белгән кеше үзе күрә. Без күп яктан упкынга тәгәрибез кебек. Әмма шулар арасында татарлар ныклырак, ышанычлырык. Бу үзе үк рух дигән сүз. Аның эчендә рухы булмаса, ул күңел төшенкелегенә (депрессиягә) бирелер иде. Юкмыни урамда хәер сорашып, эчәргә сорап йөрүчеләр? Боларының рухы ул хәтле нык дип әйтеп булмый. Хәлбуки, "бомж"ларның да бөтенесен имансыз, начар кеше дип әйтмәс идем. Алар арасында да төрле бәхетсезлеккә очраганнары, объектив сәбәпләр белән шундый көнгә калганнары бар. Ни генә дисәк тә, кешелектән чыккан кешеләр - тотрыксыз алар, рухлы кешеләр түгелләр.

Кешенең рухы көчле булса, ул ачка үлсә үлә, ләкин кешенең кесәсенә керми, урламый, кеше үтерми яисә аны җәберләми. Нәкъ менә хәзер Россия җәмгыятендә елдан-ел артуга бара торган тискәре күренешләр алар шул сәламәт рух булмаудан килә. Рухы бозыла барган кешедә өмет, ышаныч юк, ул гел төшенкелеккә бирелә торган була.

**P.S. Шушы көннәрдә генә танылган галим Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның яңа китабы табадан төште (Юсупов Р.А. Уйларымда кайтам үткәннәремә... Возвращаясь к дням минувшим… - Казан: Сүз, 2011. - 352 б.). Без аны ихлас күңелдән чираттагы бай иҗат җимеше дөнья күрү белән тәбрик итәбез, галимгә зурдан-зур уңышлар һәм сәламәтлек телибез. Китап белән якыннанрак газетабызның киләсе саннарында таныштырырбыз.**

**_Нияз САБИРҖАНОВ әзерләде_**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 17.12.2011 | 7:38 | 09:08 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Якшәмбе | 18.12.2011 | 7:39 | 09:09 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Дүшәмбе | 19.12.2011 | 7:40 | 09:10 | 13:02 | 15:08 | 16:10 | 17:40 |
| Сишәмбе | 20.12.2011 | 7:40 | 09:10 | 13:02 | 15:08 | 16:10 | 17:40 |
| Чәршәмбе | 21.12.2011 | 7:41 | 09:11 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| Пәнҗешәмбе | 22.12.2011 | 7:41 | 09:11 | 13:02 | 15:09 | 16:11 | 17:41 |
| Җомга | 23.12.2011 | 7:42 | 09:12 | 13:02 | 15:09 | 16:12 | 17:42 |
| Шимбә | 24.12.2011 | 7:42 | 09:12 | 13:02 | 15:09 | 16:13 | 17:43 |

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №18 (115) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-518.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**_График буенча бу санга 15 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә._**
_Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде._
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).